**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.06.2020 Балык Бистәсе штп. № 109пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазифасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыруы хакында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 25 мартындагы 55пи номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазифасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыруы хакында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 25 мартындагы 55пи номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның 3 абзацында “ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча” сүзләрен “ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда” сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов